# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

## КАРАР № 281

**Олы Кайбыч ав.** **24 июль, 2015 ел**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2014 елның 18 октябрендәге 240 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы Указының 2 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2014 елның 18 октябрендәге 240 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү бурычы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданга (алга таба – граждан) йөкләнә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфасын (алга таба – муниципаль хезмәт) хисап елының 31 декабрь торышына муниципаль хезмәт

вазыйфасын биләгән Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә (алга таба – вазыйфалар исемлеге) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү бурычы йөкләнә.»;

б) 3 пунктта «, вазыйфалар исемлеге белән каралган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктның «в» пунктчасында:

«әгәр дә килешү суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артса,» сүзләрен «әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының соңгы өч елда отчет чорына кадәр булган гомуми кеременнән артса» сүзләренә алмаштырырга;

«килешү төзелде» сүзләрен «бу килешүләр төзелде» сүзләре белән алмаштырырга;

г) 7 пунктта:

«вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы» сүзләрен «муниципаль хезмәтнең бүтән вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы»сүзләренә алмаштырырга;

«2, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә» сүзләрен «2 пунктның беренче абзацы, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 пунктта:

беренче абзацта «җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 13 пунктта:

«килешү төзелде» сүзләрен «килешүләр төзелде (килешү төзелде»)  сүзләре белән алмаштырырга;

«әгәр дә соңгы өч ел эчендә килешү суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса,» сүзләрен «әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының соңгы өч елда отчет чорына кадәр булган гомуми кеременнән артса» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 15 пунктның икенче абзацында «вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына» сүзләрен «алар алыштырырга дәгъва иткән муниципаль хезмәт вазыйфасына» сүзләренә алмаштырырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.Г. Айзатуллловага йөкләргә.

**Совет Рәисе-**
**Кайбыч муниципаль**
**районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**